ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясының аерым нигезләмәләренең һәм «Татарстан Республикасында беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 7 пунктының өченче – алтынчы абзацларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 3 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасында беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында» 2018 елның 11 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 29 (I өлеш).

## 2 статья

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. 16 яшькә кадәрге балага (гомуми белем бирү оешмасында белем алучыга – ул укуын тәмамлаганчы, әмма аңа 18 яшь тулганчы гына) айлык пособие 2023 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән гражданнарга әлеге айлык пособие аны бирү срогы тәмамланганчы түләнә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 23 декабрь
№ 97-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ